# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**29 октябрь 2022 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә 2022 елның 29 октябрендә "Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы студентларыннан, гайлә әгъзасы махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаиләләрдән кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә" соравы буенча узган гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

- урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Загорье торак пункты территориясе төзекләндерүне оештыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен тракторчыга түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Загорье бистәсе зиратына керү юлларына вак таш җәю;
-Загорье торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Кече авыл бәйрәмнәрен» үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен хезмәт күрсәтү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 45 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 36 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: "РИЗА" позициясе өчен

җыенда 36 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак поуктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. “Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы студентларыннан, гайлә әгъзасы махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаиләләрдән кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Загорье торак пункты территориясе төзекләндерүне оештыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен тракторчыга түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Загорье бистәсе зиратына керү юлларына вак таш җәю;

-Загорье торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Кече авыл бәйрәмнәрен» үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен хезмәт күрсәтү) соравы буенча үзара салым кертү буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында бастырырга (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районының
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Г.И. Әскәрова